**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Аксубай муниципаль районы Иске Татар Әдәмсуы авыл жирлеге башлыгы**

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Глава Старотатарско-Адамского сельского поселения Аксубаевского муниципального района**

**423055 Республика Татарстан Аксубаевский район с. Старый Татарский Адам, ул. Центральная дом 20**

Тел. (8-84344-4-35-84) ОГРН 1021605359610,
ОКПО 27839564, ИНН/КПП 1603000965/160301001
E-mail: *Stadam.Aks@tatar.ru*

---

КАРАР

15 ноябре 2024 ел № 4

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Иске Татар Әдәмсуы авыл җирлеге
Тахтала авылы
гражданнарының үзара салым акчаларын
кертү һәм алардан файдалану
мәсьәләсе буенча гражданнар
җыенын билгеләү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 ел, 6 октябрь, 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 ел, 28 июль, 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Аксубай муниципаль районының «Иске Татар Әдәмсуы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. 2024 елның 28 ноябрендә 13.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы Аксубай районы Тахтала авылы Мәктәп урамы, 4 нче йорт адресы буенча урнашкан клуб бинасы янында Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Татар Әдәмсуы авыл җирлегенең Тахтала авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының беренче этабын билгеләргә.

2.Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләләрне расларга:

Аксубай муниципаль районы Иске Татар Әдәмсуы авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 төркем инвалидлары, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, махсус хәрби операциядә катнашучыларны (хәрби хезмәткәрләрне, контракт буенча хезмәткәрләрне, волонтерларны) һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергәләп яшәүче ата-аналар, ир белән хатыннар, балигъ булган балалар)түләүдән азат итүдән тыш, 720,21 сум күләмендә 2025 елда үзара салым кертү һәм алдагы эшләрне

башкару буенча әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме?:

1. 1. Җирлек торак пунктлары чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге;
Тахтала торак пункты урамнары буйлап торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау һәм карап тоту (вак таш, туфрак вагы сатып алу, ташу, салу, тигезләү, комнан һәм туфрактан нигез салу, эшләр өчен килешү буенча түләү); Тахтала авылы эчендәге юлларны карап тоту, кышкы вакытта урамнарны кардан чистарту (килешүе буенча хезмәтләр өчен түләү).

2. Җирлек торак пунктлары чикләрендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын үткәрүне тәэмин итү:
- янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү (янгын сүндерү машинасын тоту: ягулык-майлау материаллары сатып алу).

3. Җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру, аның предметы җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен, социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалана алуына таләпләрне үтәү, күрсәтелгән Кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:
- урамнарны яктырту җайланмасы (торак пункт чикләрендә урамнарны яктыртуны оештыруны тәэмин итү өчен товарлар сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү, Тахтала авылы урамнарында энергия саклаучы лампалар сатып алу, сатып алу, урнаштыру)

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга: http://Aksubayevo.tatarstan.ruһәмхокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга:http://pravo.tatarstan.ru/

Аксубай муниципаль районы
Иске Татар Әдәмсуы авыл
җирлеге башлыгы: Э. М. Хөснуллина

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ "АКСУБАЕВСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН" Р 06-658/13 СОВЕТ СТАРОТАТАРСКО-АДАМСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ